**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 март № 127

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы; 2015 ел, 6 май, 325 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1 нче пунктында «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1 бүлектә:

1.1 нче пунктта «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 нче пунктта «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнар» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнары түбәндәгеләрдән тора:

турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнар;

социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәт күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында билгеләнгән закон таләпләре нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле финанс чаралары күләме (статьялар буенча чыгымнар нормаларын билгеләнгән стандартларга җиткерү коэффициентларын исәпкә алып).

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында бүлмәләрне җиһазландыруга таләпләр һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары биналарын эксплуатацияләүнең техник нормалары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен кирәкле финанс чаралары күләме (статьялар буенча чыгымнар нормаларын билгеләнгән стандартларга җиткерү коэффициентларын исәпкә алып).

Социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативлары – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында билгеләнгән закон таләпләре нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, бүлмәләрне җиһазландыруга таләпләр һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары биналарын эксплуатацияләүнең техник нормалары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен кирәкле финанс чаралары күләме (статьялар буенча чыгымнар нормаларын билгеләнгән стандартларга җиткерү коэффициентларын исәпкә алып).»;

1.4 нче һәм 1.6 нчы пунктларда «Социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнар» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 нче пунктның беренче абзацында «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнарын» сүзләренә алмаштырырга;

1.9 нчы пунктта:

беренче абзацта «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнары» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары 1 көнгә бер койка-урынга исәпләгәндә билгеләнә.»;

1.10 нчы пунктта «Социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнар» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары, социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

исемдәге «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны» сүзләрен «турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NFZ^{t}_{nvf} = R_{FOT} + R_{miob} + R_{opit} + R_{ohby} + R_{othbn} + R_{ot\mathrm{sgn}} + R_{ogpl} +$$
$$+ R_{oys} + R_{oty} + R_{omiomp} + R_{omps} + R_{oyml} + R_{okp} + R_{oii} + R_{okmm},$$

монда:

$NFZ^{t}_{nvf}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары;

$R_{FOT}$ – социаль хезмәтләр төрләре яктылыгында социаль хезмәтләр күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) кыйммәте;

$R_{miob}$ – социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүче персоналны йомшак инвентарь һәм махсус кием белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{opit}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны азык-төлек белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{ohby}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны хуҗалык-көнкүреш хезмәтләре белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{othbn}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{ot\ sgn}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{ogpl}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны яздырып алына торган басмалар, газеталар һәм журналлар белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{oys}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында элемтә хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;

$R_{oty}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында транспорт хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;

$R_{omiomp}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүче медицина персоналын йомшак инвентарь һәм махсус кием белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{omps}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны медикаментлар һәм бәйләү чаралары белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{oyml}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны дәреслекләр һәм методик әдәбият белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{okp}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны канцелярия әсбаплары белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{oii}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны уеннар һәм уенчыклар белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{okmm}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны мәдәни-массакүләм чаралар белән тәэмин итүгә чыгымнар.»;

3 бүлектә:

3.1 нче пунктта «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнар» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлектә:

исемдәге «социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнар» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче, алтынчы, сигезенче абзацларны төшереп калдырырга;

4.1 нче пунктта:

«социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуның база нормативын» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарын» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.1 нче пунктчада «Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуның база нормативы ягып җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә» сүзләрен «Социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар 1 көнгә бер койга-урынга исәпләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.2 нче пунктчада «мөлкәтен карап тотуның база нормативы» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга, «мөлкәтен карап тотуның база нормативына» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарына» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.9 нчы пунктчада:

беренче абзацта «мөлкәтен карап тотуның база нормативы» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$« BNSI_{nvf}^{t} = \left(\frac{K_{nvf}^{t} + S_{nvf}^{t} + F_{nvf}^{t} + O_{nvf}}{12 \times Sq_{nvf}^{t}}\right) / (Dgg / 12) \times Sq_{nvf}^{t}, »;$$

дүртенче абзацта «социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуның база нормативы» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

«$D_{gg}$ – елдагы көннәр саны;»;

4.2 нче пунктта:

«социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуның база нормативына» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарына» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.1 нче пунктчада:

беренче абзацта «мөлкәтен карап тотуның база нормативына» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарына» сүзләренә алмаштырырга, «салым түләүләренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «мөлкәтен карап тотуның база нормативына» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарына» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «мөлкәтен карап тоту нормативы» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына факттагы норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.2 нче пунктчада:

беренче абзацта «Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тоту нормативы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының ягып җылытыла торган мәйданының 1 кв.метрына исәпләгәндә билгеләнә» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына факттагы норматив чыгымнар 1 көнгә бер койка-урынга исәпләгәндә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

4.2.3 нче пунктчада:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына факттагы норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$NSI_{i\,nvf}^{t} = \frac{K_{i\,nvf}^{t} + S_{i\,nvf}^{t} + B_{i}^{t} + F^{t}{}_{nvf} + O_{nvf}}{12 \times Sq_{i\,nvf}}$$ ,»;

җиденче абзацны төшереп калдырырга;

4.2.7 нче пунктны төшереп калдырырга;

5 бүлектә:

исемдәге «хезмәтләрне финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибе» сүзләренә алмаштырырга, «хезмәтләрне финанслау нормативларына төзәтү коэффициенты» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтү коэффициенты» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 нче пунктта:

беренче абзацта «хезмәтләрне финанслау нормативлары» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «хезмәтләрне финанслау нормативлары» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 нче пунктның беренче һәм өченче абзацларында «хезмәтләрне финанслау нормативларына» сүзләрен «социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарга» сүзләренә алмаштырырга;

6 бүлектә:

исемдәге һәм 6.1 нче пункттагы «социаль хезмәт күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативына» сүзләрен «турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнарга» сүзләренә алмаштырырга;

6.2 нче пунктта:

беренче һәм дүртенче абзацларда «социаль хезмәт күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативына» сүзләрен «турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнарына» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «социаль хезмәт күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативы» сүзләрен «турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

6.3 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларда турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:»;

7 бүлекнең 7.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Социаль хезмәтләр күрсәтүгә социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FO_{i\,nvf}^{t} = ((\sum_{n=1}^{w}\sum_{p=1}^{q}\sum_{f=1}^{s} NFZ_{nvf}^{t} \times N_{i\;fo}^{t}) + (\sum_{n=1}^{w} NF_{nvf}^{t} \times KNF_{i\,nvf}^{t} \times N_{i\;fg}^{t}) +$$

$$+ (BNSI_{nvf}^{t} \times KNSI_{i\,nvf}^{t} \times N_{i\;po}^{t} \times D_{gg})) - DD_{i\,chpy} + Nl_{i},$$

монда:

$FO^{t}_{i\,nvf}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү;

$NFZ^{t}_{nvf}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле норматив чыгымнары;

$N^{t}_{i\,fo}$ – күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең факттагы саны;

$NF^{t}_{nvf}$ – гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү үзәкләрендәге һәм социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү бүлекләрендәге өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында булган оешмаларда һәм ярымстационар формалы оешмаларда социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар;

$KNF^{t}_{i\,nvf}$ – гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү үзәкләрендәге һәм социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү бүлекләрендәге өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында булган оешмаларда һәм ярымстационар формалы оешмаларда социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтү коэффициенты;

$N^{t}_{i\,fg}$ – халык саны;

$BNSI^{t}_{nvf}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнары;

$KNSI_{I}{}^{t}_{nvf}$ –$i$ социаль хезмәт күрсәтү оешмасының социаль хезмәтләр күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарына төзәтү коэффициенты;

$N^{t}_{i\,po}$ – койкаларның планлаштырылган саны;

$D_{gg}$ – елдагы көннәр саны;

$DD_{i\ chpy}$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керем;

$Nl_{i}$ – социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен кирәкле мөлкәт алар буенча салым салу объекты булып танылган салымга түләнгән акча күләме, шул исәптән җир салымнары;

$w$ – социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр исемнәре саны;

$q$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләрдән файдаланучылар категорияләре саны;

$s$ – социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәт күрсәтү формалары саны.».

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков